ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 50-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Л.А. Якунин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 50-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2025 елның 20 феврале
№ 188-VII ДС

проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
Л.А. Якунин тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 3, № 6 (III өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 28 (I өлеш), № 45 (I өлеш); № 74 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 24 статьяның 2 пунктындагы икенче абзацында «керемнәр, шулай ук» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе Бюджет кодексының $93^{9}$ статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән бюджет кредитлары,» сүзләрен, «шулай ук финанс белән тәэмин итү чыганагын инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган бюджет кредитлары» сүзләреннән соң «, Россия Федерациясе Бюджет кодексының $93^{9}$ статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән бюджет кредитлары» сүзләрен өстәргә;

2) 29 статьяның 3 пунктында «бурыч йөкләмәләрен түләү,» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе Бюджет кодексының $93^{3}$ статьясындагы 1 пунктының алтынчы абзацы һәм $93^{9}$ статьясындагы 2 пункты нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана торган бюджет кредитлары бирү тәртипләрендә каралган инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү,» сүзләрен, «тулыландыру» сүзеннән соң «(Россия Федерациясе Бюджет кодексының $93^{6}$ статьясында каралган бюджетның бердәм счетындагы калган акчаларны тулыландыруга бюджет кредитларына карата)» сүзләрен өстәргә;

3) $29^3$ статьяның 5 пунктында «инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны» сүзләреннән соң «һәм казначылык инфраструктура кредитларын» сүзләрен өстәргә;

4) 31 статьяның $4^1$ пунктында:

а) беренче абзацта «инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны» сүзләреннән соң «һәм казначылык инфраструктура кредитларын» сүзләрен өстәргә;

б) икенче абзацта «инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны» сүзләреннән соң «һәм казначылык инфраструктура кредитларын» сүзләрен өстәргә;

5) 77 статьяның 3 пунктындагы сигезенче абзацында «инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны» сүзләреннән соң «һәм казначылык инфраструктура кредитларын» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Россия Федерациясе закон актлары аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору, Россия Федерациясе закон актлары аерым нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану турында һәм 2025 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» Федераль законның 12 һәм 15 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 26 декабрендәге 488-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) кабул ителүгә бәйле рәвештә эшләнде.

Федераль закон белән Россия Федерациясе Бюджет кодексына казначылык инфраструктура кредитлары турындагы яңа $93^9$ статья өстәлде. Казначылык инфраструктура кредитлары, федераль бюджет турындагы федераль законда казначылык инфраструктура кредитлары бирү каралган очракта, Федераль казначылык тарафыннан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә федераль бюджетның бердәм счетындагы вакытлыча тотылмый торган акчалар исәбеннән унбиш елга кадәрге срокка бирелә.

Казначылык инфраструктура кредитларын бирү максатлары һәм казначылык инфраструктура кредитларыннан файдаланган өчен түләү күләмнәре федераль бюджет турындагы федераль закон белән билгеләнә.

Бер үк вакытта Федераль закон белән бюджет кытлыгының иң чик күләмен һәм Россия Федерациясе субъектының дәүләт бурычының иң чик күләмен алынган казначылык инфраструктура кредитлары суммасына арттыру мөмкинлеге билгеләнә. Казначылык инфраструктура кредитларына шулай ук Россия Федерациясе субъекты хисаплашуларының иң чик күләме буенча чикләүләр кагылмый.

Моннан тыш, Россия Федерациясе субъектларының эчке дәүләт хисаплашуларын гамәлгә ашыру максатларына, шул исәптән, инфраструктура бюджет кредитларын һәм казначылык инфраструктура кредитларын җәлеп итеп инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү дә керә.

Казначылык инфраструктура кредитлары бирелгән очракта, шулай ук бюджет турындагы законга үзгәрешләр кертмичә генә җыелма бюджет язмасына үзгәрешләр кертү өчен нигезләрне төгәлләштерү дә күздә тотыла.

Россия Федерациясе Бюджет кодексының әлеге үзгәрешләренә бәйле рәвештә, закон проекты белән Татарстан Республикасы Бюджет кодексының шундый ук нигезләмәләрен аларга туры китерү тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә башкаларын кабул итү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итмәячәк һәм Татарстан Республикасы бюджетының керем өлешенә тәэсир ясамаячак.